**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2019 № 438

**2015 елның 6 мартындагы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый Совет төзү турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 177 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый Совет турында”гы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында”гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР КЫЛА**:

1. 2010 елның 6 мартындагы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет төзү турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма

комитетының 177 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.9 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

“3.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составына түбәндәгеләр керә алмый:

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте вазыйфалары; муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар;

мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып баручы иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре;

мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмалар җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) һәм хезмәткәрләре;

2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында”гы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмый.”.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкче** **Р. М. Заһидуллин**